СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.2019 Алабуга шәһәре № 370

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2008 елның 30 апрелендә чыккан 172 сандагы «Алабуга муниципаль районы башлыгы каршында Иҗтимагый совет турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 21 июлендә чыккан 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының оешмалары, предприятиеләре, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү, социаль һәм сәяси мәсьәләләрне хәл иткәндә иҗтимагый килешүләргә ирешү, гражданнарның фикерләрен исәпкә алу, муниципаль берәмлекнең тотрыклы социаль-икътисадый үсешен булдыру, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2008 елның 30 апрелендә чыккан 172 сандагы «Алабуга муниципаль районы башлыгы каршында Иҗтимагый совет турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Алабуга муниципаль районы башлыгы каршында Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәнең 2.2.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Советның төп бурычлары :

- гражданлык хокукый аңны формалаштыру һәм үстерү;
- гражданнарның дәүләт эшчәнлегенә ышаныч дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук дәүләтнең гражданлык җәмгыяте институтлары белән тыгыз хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- социаль конфликтларны кисәтү һәм хәл итүгә булышлык;
- кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән граждан инициативаларын гамәлгә ашыру ;
- федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, башка органнар һәм оешмалар эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү;
- җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түзмәүчелекне формалаштыру;
- үз вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәштә катнашу;